ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16 май 2019ел № 2518

Башкарма комитетның 2019 елның 6 мартындагы 1158 нче карары белән расланган җайга салына торган тарифлар буенча Яр Чаллы шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча даими йөртүләрне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне кайтаруга шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24, 5.25 пунктлары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 6 мартындагы 1158 нче карары белән расланган җайга салына торган тарифлар буенча Яр Чаллы шәһәренең муниципаль маршрутлары буенча даими йөртүләрне гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә алынып бетмәгән керемнәрне кайтаруга шәһәр бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Башкарма комитетка әлеге тәртипнең 9 пунктында каралган гариза һәм документлар кергән көнне Башкарма комитет Җитәкчесе аларны карап тикшерә һәм карап тикшерү өчен Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгына җибәрә.»;

2) 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Башкарма комитетның финанс идарәсеннән карар проекты кергән көнне Башкарма комитет Җитәкчесе аны имзалый һәм аны теркәү өчен Башкарма комитетның финанс идарәсенә җибәрә.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин